**Каюмова Гөлия Илдус кызы,**
*филол. фән. канд., өлкән фәнни хезмәткәр,*
*ТР ФАнең Татар энциклопедиясе*
*һәм төбәкне өйрәнү институты,*
*Казан шәһәре, Татарстан.*
*e-mail: guliya.kayumova@yandex.ru*

УДК 82-7

# ТАТАР ҺӘМ РУС КОМЕДИЯЛӘРЕНДӘ КӨЛКЕ УЯТУЧЫ ОХШАШЛЫК ҮРНӘКЛӘРЕ (ОБРАЗЦЫ КОМИЗМА СХОДСТВА В ТАТАРСКИХ И РУССКИХ КОМЕДИЯХ)

# THE EXAMPLES OF THE COMICALITY OF SIMILARITY IN THE TATAR AND RUSSIAN COMEDIES

**Аннотация.** В статье рассматриваются комедии известного татарского драматурга Р.Хамида и видного русского писателя Н.Гоголя с точки зрения комизма сходства.

**Ключевые слова:** комедия, сатирический персонаж, комизм сходства.

**Abstract.** The article discusses the comedies of the well-known Tatar playwright R.Hamid and the famous Russian writer N.Gogol from the point of view of the comicality of similarity.

**Keywords:** a comedy, a satirical character, the comicality of similarity.

Комедия әсәре үз иленең һәм үз чорының гореф-гадәтләрен, тәртипләрен гәүдәләндерергә, иҗтимагый гаделсезлекләрне, кеше холкындагы тискәре якларны фаш итәргә бурычлы, шулай эшләгәндә генә ул җәмгыятьтәге, кеше характерындагы языкларны төзәтү, бөекне, камиллекне яклап чыга алу көченә ирешә. Шул максаттан әдипләр, дөньяви-иҗтимагый, рухи-әхлакый кыйммәткә ия мәсьәләләрне яктыртканда, төрле традицион яки традицион булмаган сәнгатьчә сурәтләү чараларыннан файдаланалар, чорның актуаль проблемаларын тагын да үтемлерәк җиткерү өчен, яңадан-яңа сәнгатьчә алым-чараларга мөрәҗәгать итәләр. Татар әдәбиятында да, рус әдәбиятында да моның уңышлы мисаллары шактый. Бу уңайдан татар һәм рус әдипләренең әсәрләрен шушы юнәлештә карап үтү урынлы булыр.

Күренекле татар драматургларының берсе Р.Хәмид «Чабаталы чәүчәләк» комедиясендә туган тел мәсьәләсен үзгә бер сәнгатьчә югарылыкта күтәреп чыга. «Чабаталы чәүчәләк» – карнаваль көлүгә нигезләнгән театральләштерелгән музыкаль тамаша, фантастик әсәр, гротеск алымыннан уңышлы файдаланылган халыкчан комедия. Б.Дземидок үзенең «О комическом» хезмәтендә көлүнең 6 типологик төрен тасвирлый [3, с. 7-60]. Әлеге комедия шулар арасында авторның «нормадан читкә китү теориясе»нә туры килә.

Тамашадан аңлашылганча, зур булмаган татар авылында хәлле тормышта яшәүче Исәнали оныкларының татарча бер авыз сүз белмәүләренә бик борчыла: “Болай барса, балаларыбызның балаларының балалары – торыннарыбыз кемнәр булып бетәрләр?! Нәселләренең Никулай-Микулайларга әверелеп бетүләрен аңламыйлар микәнни алар?! Киләчәктә үзләренең каберләренә дә борылып карамаячаклар ич алар, кая инде ул кадерләрен белү...” [8, б. 8]. Үз балалары да янында түгел. Төрле милләт кешеләре белән тормыш корып, читтә яшәп яталар. Алар да туган нигезләренә, туган телләренә битараф. Пьесаның сюжеты үзенчәлекле корылган: персонажлар үз язмышларын, аларны борчыган мәсьәләләрне такмакка салып сөйлиләр. Әлеге такмакларның иҗтимагый вазифасы шунда: аерым бер кеше язмышында шундый ук башкалар язмышы, ягъни бөтен бер халык язмышы яктыртыла. Бу – драматургның сюжет төзүдә сәнгатьчә табышы.

Гакыйль исемле егет авыл баласының туган теленнән, гореф-гадәтләреннән читләшүенә ул тәрбияләнеп үскән мохитнең һәм мәктәпнең йогынтысы зур булуын әйтә. Исәналинең бу хәлгә бик ачуы чыга. Исәнали – сатирик персонаж. Комедия героена хас булганча, ул “таләпчән”: туган телне җәмгыятькә кайтаруны “таләп итә”. “Баланы туган телдән биздерүдә мәктәп гаепле” дигән уйны күңеленә салып куйган чабаталы чәүчәләк үзенең хаклылыгына ахмакларча ышанып, ахмак гамәлләр кылып йөри. Аның милләт кайгысын “кайгыртып йөрүе” гадәттән тыш арттырылган. Вакыйгалар шартлылыкка корылган. Күренешләр әкияттәгечә бик тиз арада булып уза. Исәнали егеткә атланган хәлдә тиз генә мәктәп директоры янына да, район мәгариф идарәсенә дә, мәгариф министрлыгына да барып җитә. Исәналинең, балаларына, оныкларына туган телнең кадерен төшендерә, аңа хөрмәт уята белмәүдә үз гаебенең дә зурлыгын аңламыйча, аларны туган телдән биздерүдә бары хатынын, оныкларының әти-әниләрен һәм мәгариф өлкәсендә эшләүчеләрне генә гаепләп чәүчәләве көлке. Күрәбез ки, баш герой характерының әйдәүче сыйфаты әсәрнең исеменә үк чыгарылган. Аягына чабаталарын киеп, күпме генә чәүчәләп йөрмәсен агай, мәсьәлә аның файдасына хәл ителми.

Чабата деталенең әлеге образны ачуда, шулай ук иҗтимагый мәгънәне җиткерүдә әһәмияте зур. Исәналинең, татар түрәләренә ияреп, чабатасын түргә элүе – бу аның шуларга охшарга тырышу галәмәте. Моңа охшаш икенче бер күренешне билгеләп үтү дә урынлы, ягъни татар халкының, ана теленә карата битарафлык күрсәтеп, рус мәдәниятен генә үзләштерергә омтылуы, рус телендә генә сөйләшүе аларга охшарга тырышу кебек аңлашыла. Шушы охшарга тырышу күренеше көлке уята.

Драматург персонажларны гәүдәләндерүдә, шул рәвешчә пьесаның иҗтимагый әһәмиятен җиткерүдә тышкы охшашлык алымыннан да отышлы файдалана. Исәнали белән Гакыйль күргән мәктәп директоры да, район мәгариф идарәсе җитәкчесе дә, мәгариф министрлыгының “бик тә җаваплы хезмәткәре” дә – бер үк исемдәге, бер-берсенә бик тә охшаш, бары париклары һәм фамилияләрендәге бер хәреф белән генә бераз аерылып торучы кешеләр. Болар үзләре дә, ике телне бергә кушып, Гакыйль сүзләре белән әйтсәк, “воляпюк” телендә сөйләшәләр. Берсен берсе «кабатлаучы» (ягъни «дубльләштерүче» (В.Пропп)) әлеге ханымнарның тышкы кыяфәтләре генә түгел, уйлары, фикер сөрешләре дә бер-берсенекеннән аерылмый. Гакыйль әйтмешли, “бөтен кыланышлары, мәнсезлекләре нәкъ бертөсле” [8, б. 48]. Алар, үзләре татар булсалар да, рус теленә, рус мәдәниятенә өстенлек бирәләр. Әлеге “авыл гыйбадлары”ның татар телен яклап әйткән сүзләре аларга сәер һәм көлке кебек тоела. Болар өстән кушканны бер каршылыксыз үтәүче роботлар, татар телен кысуда зур роль башкаручы «тоталитар система кораллары» [7, с. 200] буларак күзалланалар. Бу күренешләр мәгариф системасы торышына пародия кебек аңлашыла. Охшашлык китереп чыгарган шундый гайре табигый хәлләр күз яше аша көлдерә һәм авторның хәзерге чынбарлыкка ирониясе булып тора. Әлеге алым ярдәмендә әдип татар теленең бөек тел булуын яклап чыга, үз милләтеңнән, үз телеңнән йөз чөереп, башкаларга иярүнең хурлык һәм ахмаклык билгесе булуына төшендерә.

Әдәбиятта, гомумән, бер-берсенә охшаган кеше образлары беренче тапкыр борынгы Рим драматургы Тит Макций Плавт комедияләрендә барлыкка килә. Рус әдәбиятында комедия әсәре язу осталарының берсе Н.Гогольнең «Ревизор» сатирик комедиясендәге Бобчинский белән Добчинскийны да көлке уятучы охшашлык үрнәкләре буларак карап үтәргә мөмкин. Сюжеты ягыннан К.Тинчуринның «Американ» комедиясе белән аваздаш «Ревизор»ны Ә.Исмәгыйлев тәкъдим иткән бүленештәге [4, б. 72,73] «гел тискәре геройлардан гына торган комедияләр» төркеменә кертеп карау хак булыр. Дөрестән дә, бу әсәрдә бер генә уңай образ да табу мөмкин түгел. Анда «городничий Сквозник-Дмухановскийлар өере, Русиянең черек крепостнойлык чоры» [5, б. 224] үткен фаш ителә. Әсәрдә искәртелгәнчә, “тәбәнәк кенә, кыска гына буйлы, һәрнәрсәне белергә бик кызыксынган, бер-берсенә бик нык охшаган, икесе дә түгәрәк кенә корсаклы, икесе дә ашыгып сөйләүче, сөйләгәндә бик күп кул бутаулар, хәрәкәтләр ясаучы” [2, б. 7] шәһәр алпавытлары Добчинский белән Бобчинский да Р.Хәмид персонажлары кебек үк тышкы кыяфәтләре, хәрәкәтләре белән генә бер-берсен «кабатлап» калмыйлар, ә рухи халәтләре, фикер сөрешләре, омтылышлары, карашлары да бертөрле, ягъни үзләренә генә хас индивидуаль үзенчәлекләрдән азат персонажлар буларак күзалланалар. Исемнәре бер үк, фамилияләре охшаш әлеге кешеләр – шәһәр гайбәтен җыеп һәм таратып йөрүче эшлексез, булдыксыз һәм мәгънәсез, әмма үзләренчә җәмгыятькә кирәкле һәм файдалы булырга тырышучы, һәр кыланышлары, сөйләгән сүзләре көлке уятучы сатирик типлар. Аларны бер-берсеннән башка күз алдына китереп булмый: болар – пьесаның иҗтимагый әһәмиятен җиткерүдә берсе икенчесен тулыландырып һәм “бизәп торучы” ярдәмче образлар. Шәһәрнең алдынгы гайбәтчеләре буларак, ревизор килү хәбәрен дә беренчеләрдән булып җиткерүчеләр – алар. «Тулысынча бертөсле кешеләр үзара талаша һәм тиргәшә башласалар, көлү тагын да көчәя» [6, с. 40]. Әлсерәп килеп кергән Добчинский белән Бобчинский бер-берсен бүлдерә-бүлдерә “гадәттән тыш вакыйга” турында хәбәр итәргә ашыгалар, юктан да сүзгә киләләр, кулларын бутый-бутый сөйлиләр:

Бобчинский: Пётр Иванович белән гостиницага барып керсәк...

Добчинский (аны бүлеп): Рөхсәт итегез, Пётр Иванович, мин сөйлим.

Бобчинский: ...Комачауламагыз инде, мин сөйлим, комачауламагыз!.. “Бу яшь егет – Петербургтан килгән чиновник, – ди. – Фамилиясе – Иван Александрович Хлестаков. ..Үз-үзен тотуы бик гаҗәп, – ди аның: ике атнадан бирле тора … бер тиен дә түләргә теләми”, – ди. Шул сүзләрне әйткәч тә, минем кылт итеп исемә төште. “Э!” дим мин Пётр Иванович…

Добчинский: Юк, Пётр Иванович, “Э!” дип мин әйттем.

Бобчинский: Башта сез әйттегез, соңыннан мин дә әйттем. Пётр Иванович белән без, икәүләп, “Э!” дидек [2, б. 17, 19]. Күрәбез ки, комедия героеның акыл дәрәҗәсе фаш ителсен өчен, аның авызыннан бер-ике сүз чыгу да җитә. Ремаркадагы автор сүзләре дә аның фикерләү дәрәҗәсен ачарга ярдәм итә. Бобчинский, мәсәлән, әлеге дә баягы шул Петербург чиновнигын тасвирлаганда: “Йөзе бик уйчан, кыяфәте, кыланышлары һәм… монда (маңгае тирәсен кулы белән күрсәтеп) бик күп, бик күп нәрсәләр барлыгы күренеп тора” – ди [2, б. 18], ләкин комедия персонажына хас булганча, ул башта нәрсәләр барлыгы хакында төгәл генә берни дә аңлата алмый, бик акыллы кыяфәт китереп, кулларын болгау белән генә чикләнә. Буш һәм томана бәндәнең үзе кебек үк бушкуыкны зур, дәрәҗәле кеше итеп кабул итүе комедия, аеруча сатира персонажына хас күренеш. Аның “сыек” аңы чын идеалларны кабул итә дә алмый. Гомумән, пьесада городничий һәм аның даирәсендәге башка сатирик типлар сатира законнарына ярашлы рәвештә үзләре һәм үз эшләре тарафыннан һәрдаим фаш ителеп торалар. Ревизор килү хәбәре үк шәһәрнең “терәкләре”н пошаманга, алай гына да түгел, куркуга төшерә,

бер-берсенә карата бертуктаусыз шелтә сүзләре әйтелә, гаепле эшләренә, кимчелекләренә төртеп күрсәтелә, ниһаять, “судан коры чыгу” өчен, ялган ревизорга акча биреп котылмакчылар, шул рәвешчә һәркайсының, шул исәптән “ревизор”ның да чын йөзе тулысынча ачыла. Алар, тулаем алганда, тышкы кыяфәтләре белән бер-берсеннән аерылсалар да, максат-омтылышлары, тормышка мөнәсәбәтләре, рухи ярлылыклары ягыннан охшашлар. Әлеге эчке охшашлык “ревизор”га ришвәт биреп ярарга тырышу күренешендә аеруча көчәя. Шул охшашлык китереп чыгарган күңелсез хәлләр, “тузга язмаган” эш-гамәлләр, мәгънәсез сүзләр, сай фикерләр көлке уята. Н.Гоголь иҗатында бер-берсенә охшаган персонажларны шактый очратырга була. Алар барысы да иҗтимагый, әхлакый мәсьәләләрнең актуальлеген җиткерүдә алыштыргысыз роль уйныйлар. Рус әдәбиятында шулай ук А.Островскийның «Чибәр ир» («Красавец мужчина») комедиясендәге ике эшсез – Пьер белән Жоржны, «Шаяннар» («Шутники») комедиясендә Недоносков һәм Недоростковны да көлке уятучы охшашлык үрнәкләре буларак карарга мөмкин.

Һәр язучы – татармы ул, русмы, чит илнекеме – әсәрендә үзе яшәгән һәм иҗат иткән чорның актуаль проблемаларын көн кадагына куярга, төрле сәнгатьчә чаралар ярдәмендә аларның мөһимлеген укучы аңына җиткерергә омтыла. Комедия жанрында көнүзәк мәсьәләләрне үтемле яктыртуның иң көчлесе – сатира. «Югары эстетик идеалларга каршы килүче бөтен нәрсә сатираның сурәтләү объектына әверелә» [1, с. 87]. Аның хөкеменнән бер генә кимчелек тә, җитешсезлек тә качып кала алмый. Югарыда карап үтелгән комедияләрдә драматургларның иҗтимагый, шәхси бозыклыкларны, тискәре күренешләрне сатира камчысы белән камчылауда көлке уятучы охшашлык алымыннан уңышлы файдаланулары күренде. Алар, тышкы охшашлыкка тиңдәш рәвештә эчке охшашлыкны, ягъни тар карашлар, берьяклы теләк-омтылышлар охшашлыгын гәүдәләндереп, иҗтимагый һәм шәхси кимчелекләрне фаш итәләр, шул рәвешчә эстетик идеал бөеклегенә, иҗтимагый-әхлакый камиллеккә омтылалар.

**Әдәбият**


1. Борев Ю. Комическое или о том, как смех казнит несовершенство мира, очищает и обновляет человека, и утверждает радость бытия. – М.: Изд-во «Искусство», 1970. – 272 с.
2. Гоголь Н.В. Ревизор: Пьесалар. З.Солтанов тәрҗемәсе. – Казан: Татгосиздат, 1952. – 5-100 б.
3. Дземидок Б. О комическом. – М.: «Прогресс», 1974. – 223 с.
4. Исмәгыйлев Ә. Комедияләр турында (Комедиянең жанр үзенчәлеге). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 176 б.
5. Исмәгыйлев Ә. Сәнгать һәм жанр. – Казан: «Сүз» нәшр., 2011. – 360 б.
6. Пропп В. Я. Комизм сходства / Проблемы комизма и смеха. – М.: «Искусство», 1976. – 183 с.
7. Ханзафаров Н.Г. Татарская комедия: Истоки и развитие. – Казань: «Фэн», 1996. – 267 с.
8. Хәмид Р. Чабаталы чәүчәләк: ике бүлекле тамаша. – Казан, 2001. – 56 б. (Кулъязма).



**Киндикова Нина Михайловна,**

*д.филол.н., профессор*
*Горно-Алтайского государственного университета*
*г. Горно-Алтайск*



УДК 81


# ЭТНОЭСТЕТИЧЕСКИЕ ОСОБЕННОСТИ ОДНОГО СТИХОТВОРЕНИЯ

# AMNESTICESCOE FEATURES OF ONE POEM


**Аннотация.** В статье анализируется этнокультурные особенности стихотворения алтайского поэта Л.В.Кокышева. Методом литературной герменевтики объясняется смысл отдельных строф.



**Ключевые слова:** этнокультурные традиции, национальный колорит, строфа, героический эпос.



**Abstract.** The article considers ethno-cultural peculiarities of Altaic poems of the poet L.V. Kokysheva. Method of literary hermeneutics explains the meaning of individual verses.



**Keywords:** ethno-cultural traditions, national color, verse, heroic epic.


Была ли попытка подстрочного перевода стихотворения «На земле Алтая обитают духи отцов» алтайского поэта Лазаря Васильевича Кокышева (1933-1975) на русский и другие языки неизвестно. Но исследователи литературы часто цитируют строки именно из этого стихотворения, потому что смысл его загадочен, философичен, глубоко национален, не всякому подвластен для поэтического перевода. В оригинале это стихотворение существует без названия, впервые опубликовано в сборнике автора под названием «Снят-